# Чишмә башы

**Февраль, 2026**

***Хөрмәтле Ир-егетләребез!***

***Барлык буын вәкилләрен берләштереп, ир-атларыбызның ил күләмендә уздырылучы иң төп бәйрәме - Ватанны саклаучылар көне белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез!***

***Әлеге бәйрәм –тарихыбызда гаять үзенчәлекле. 23 февраль көнне без Туган илебезне саклаган һәм саклауны дәвам итүче Русия хәрбиләренә хөрмәт һәм чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Үзебезнең рәхмәт сүзләребезне Бөек Ватан сугышы һәм локаль конфликтлар ветераннарына, бүгенге көндә хәрби операциядә илебез тынычлыгын саклаучы батырларыбызга җиткерәбез.***

***Үз йортыңны саклау –тәүге бурыч, аны үтәү - һәркем өчен намус эше. Нәкъ менә шуның өчен 23 февраль гомумхалык бәйрәменә, көчле рухлы, батыр, кыю кешеләр бәйрәменә әверелә бара. Безнең территориядә яшәүче теләсә кайсы кеше – хәрби вазифасын үтәүчеме ул яисә тыныч тормышта хезмәт куючымы – иң беренче чиратта, үз Ватанының Сакчысы.***

***Ватанны саклаган яисә бүгенге көндә ил сагында торган һәркемгә чын күңелдән сәламәтлек, бәхет, тынычлык, иминлек телибез. Кыю йөрәкле, батыр кешеләр бәйрәме һәрчак тыныч һәм куанычлы булсын!***

**Солдат күңеле.**

**Солдат күңеле-янар хыяллар ул,**
**Үтелмәгән авыр юллар ул.**
**Постта торган һәрбер минутларда**
**Туган ягын сагыныр уйлар ул.**
**Солдат күңеле-алсу чәчәкләрнең,**
**Яшел тугайларның исләре.**
**Янып эшләп үскән колхоз кыры,**
**Тальян моңы, авыл кичләре.**
**Солдат күңеле-авыр чорыбызның**
**Ышанычы, көче, терәге.**
**Күз яшьләре тамган аналарның**
**Өметләре, керсез йөрәге.**



# Каурый каләм серләре...

## Буранлы кыш

Буранлы кыш килә дә
Бар дөньяны ак итә.
Агачларны,түбәләрне,
Юлларны күмеп китә.
Һәркем йокыдан уяныл,
Тәрәзәгә күз сала.
Яше-карты бергәләп,
Үзенә сукмак сала.
Эшчеләр эшкә барырга
Машинасын кабыза.
Юлга чыкса,кар өеме
Тора алар каршында.
Карлар ява,йомшак карлар
Биешә урамнарда.
Шау-гөр килеп,киенеп,
Чыктык без дә уйнарга.

Шакирова Ралинә
5 сыйныф

## Йомшагым.

Йомшагым да аппагым дип,
Иркәләдем песине.
Кумәч биреп,сөт эчердем-
Жәлләмәдем көнемне.
Хәзер менә йомшаккаем
Кузгалмый да урныннан.
Әллә инде тычканны да
Котәме минем кулдан?

Вәлиева Сөмбел
5 сыйныф



## Кыш

Авылга ак кыш килгән,
Агачлар ак тун кигән.
Урманнарга-кырларга
Көмеш тәңкә сибелгән.
Төнен тәрәзәгә ул
Ясап киткән бизәк тә.
Салкын булса да кышын
Рәхәт инде бигрәк тә.
Абдрахманова Камилә
5 класс

## *Сорау табышмаклар*

*1. Яшелчә бакчасында бабай, әби, онык, эт мәче, тычкан шалкан тарталар. Бакчада ничә кеше?*
*2. Кубикның һәр ягы төрле төскә буялган. Моның өчен ничә төрле буяу кирәк?*
*3. Машинага биш кәҗә бәтие утырган. Һәрберсенең 8 км юл үткәнлеге билгеле булса, машина күпме юл үткән?*
*4. Каз һәм мәче аякларының саны 8 булса, ишек алдында ничә каз бар?*
*5. Бер рәттә 8 урындык. Алия сулдан бишенче урынга, ә Рәйсә уңнан бишенче урынга утырган. Алар икесе бер урынга туры килмәгәннәрме?*
*6. Жәй көне самолет Казаннан Мәскәугә 95 мин ,ә кышын 1сәг35мин оча. Бу ни өчен шулай?*
*7. Йосыфның 7 таякчыгы бар. Бер таякчыкны урталай сындырса, аның ничә таякчыгы булыр?*



## Муса Җәлилнең тууына 120 ел

### Жырларым

Жырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле жирдә хаккыгыз!
Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә
онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.
Мин кабыздым жырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм халкык кушканны.
Жырым белән дусны иркәләдем,
Жырым белән жиндем дошманны.
Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигыремдәге чынлык, ут һәм
сөю-
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.
Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар жырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

## Ишек төбендә

Үтеп барам шулай
урам буйлап,
Парадныйда күрәм бер
бала.
Звонокка үрелә, буе
житми,
Аптырагач, карап
уйлана.
Мин балага киләм:
— Әллә, - димен, -
Звонокка буең
житмиме?
— Житми шул, - ди.
— Кая, үзем басыйм.
Бернеме, - дим, - әллә
икеме?
— Биш, ди.—Басам.
Шуннан бала әйтә:
— Абзыкай, син нинди
йөрәкле!
Әйдә качыйк хәзер,
хужа чыкса,
Икебезгә дә бирер
кирәкне!
*1942, декабрь*